**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

**2019 ЕЛНЫҢ 3 ДЕКАБРЕ** **№218**

**2020 елда "Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә үзара салым кертү турында**

2019 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасы Апас районы территориаль сайлау комиссиясе, участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре нигезендә, 2019 елның 1 декабрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде.

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамланганчы 4092 референдумда катнашучы кертелгән, референдумнда тавыш бирүдә катнашучылар саны-3078, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 75,22 % ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен 2244 кеше тавыш бирде, бу референдумда катнашучыларның 72,90% ын тәшкил итә, «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 732 кеше тавыш бирде, бу 23,78% тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Апас районы территориаль сайлау комиссиясенең 2019 елның 2 декабрендәге 78 номерлы “Татарстан Республикасы Апас районы Территориаль сайлау комиссиясенең 2019 елның 2 декабрендәге 78нче номерлы “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының “Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында” карары белән Татарстан Республикасы Апас районы «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдумны-узган, референдум нәтиҗәләре-чын дип, «Сез

җирлек территориясендә скважина бораулау;

Апас шәһәр тибындагы поселогының зираты эчендә юл салу;

контейнерлар (бункерлар) белән өстәмә контейнер мәйданчыклары урнаштыру;

МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу;

җирлек территориясен яшелләндерү;

Апас шәһәр тибындагы поселогы территориясендә су белән тәэмин итүне оештыру;

җирлектәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге

эшләрен башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен шушы җирлектә яшәүче балигъ булган, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының “Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, коляскалы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә) 2020 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендәге үзара салым кертү белән килешәсезме? соравы буенча карар кабул ителгән дип танылды.

Югарыда күрсәтелгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карар итте:

1.

Җирлек территориясендә скважина бораулау;

Апас шәһәр тибындагы поселогының зираты эчендә юл салу;

контейнерлар (бункерлар) белән өстәмә контейнер мәйданчыклары урнаштыру;

МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу;

җирлек территориясен яшелләндерү;

Апас шәһәр тибындагы поселогы территориясендә су белән тәэмин итүне оештыру;

җирлектәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге

эшләрен  башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен  шушы җирлектә  яшәүче балигъ булган, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының “Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге  территориясендә  теркәлгән  һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, коляскалы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә)  2020 елда  500 (Биш

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

«Апас шәһәр тибындагы поселогы»

муниципаль берәмлеге башлыгы Р. Ф. Хисаметдинов